РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**29.12.2025** **Чистай шәһәре** **№ 5/2**

Физик һәм юридик затларны
җир салымы буенча һәм физик
затлар мөлкәтенә салым буенча
салым салудан азат итү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 56 статьясы, «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендәТатарстан Республикасы Чистай муниципаль районының җитештерү биналары һәм индустриаль (сәнәгать) парклары территорияләрен үстерү һәм төзекләндерү, кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елга индустриаль (сәнәгать) парк буларак файдаланыла торган мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасында индустриаль (сәнәгать) парк буларак дәүләт аккредитациясе алган кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасы субъектларының физик затларын җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча салым салудан азат итәргә.

2. 2025 елга индустриаль (сәнәгать) парк буларак файдаланыла торган мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасында индустриаль (сәнәгать) парк буларак дәүләт аккредитациясе алган кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасы субъектларының юридик затларын җир салымы буенча салым салудан азат итәргә.

3. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә (Н.В. Миңнегалиев) йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов